КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 19 апрель г.Казань № 262

Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару турында нигезләмәне раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару турында нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару эшендә булышлык күрсәтергә тәкъдим итәргә.

3. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары:

«Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1996 ел, 20 август, 714 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1996 ел, 20 август, 714 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2002 ел, 31 май, 296 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару мәсьәләләре буенча аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 ел, 22 ноябрь, 646 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 ел, 18 август, 686 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару мәсьәләләре буенча аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 ел, 21 октябрь, 776 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1996 ел, 20 август, 714 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннар, үсемлекләр, гөмбәләр төрләре буенча даими эшләүче комиссия составына үзгәреш кертү хакында» 2013 ел, 31 октябрь, 815 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1996 ел, 20 август, 714 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2002 ел, 31 май, 296 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннар, үсемлекләр, гөмбәләр төрләре буенча даими эшләүче комиссия составына үзгәреш кертү хакында» 2015 ел, 1 август, 558 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 ел, 17 август, 714 нче карарының 3 пукнты.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 19 апрель, 262 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару турындагы нигезләмә

1. Төп нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып баруның төп бурычлары түбәндәгеләр: хайваннарның, үсемлекләр һәм гөмбәләрнең сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган төрләрен саклауны, аларның торышын мониторинглауны тәэмин итү, фәнни тикшеренүләр оештыру, әлеге төрләрне саклау һәм торгызу буенча чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру.

1.2. Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып баруны Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты оештыра.

1.3. Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып баруны тәэмин итү өчен даими эшләүче Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннарның, үсемлекләр һәм гөмбәләрнең сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган төрләре буенча комиссия (алга таба – Комиссия) төзелә. Комиссия турында нигезләмә һәм аның составы Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

1.4. Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару чараларын финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару тәртибе

2.1. Татарстан Республикасының Кызыл китабын алып бару тәртибе түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

хайваннарның, үсемлекләр һәм гөмбәләрнең сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган төрләре турында мәгълүмат туплау, шулай ук бу төрләргә кагылышлы мәгълүматны һәм башка материалларны саклау;

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннарның, үсемлекләр һәм гөмбәләрнең сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган төрләре торышын мониторинглауны тәэмин итү;

хайваннарның, үсемлекләр һәм гөмбәләрнең теге яки бу төрен Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертү (яки аннан чыгару);

Татарстан Республикасының Кызыл китабын әзерләү һәм бастырып чыгару;

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннарның, үсемлекләр һәм гөмбәләрнең сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган төрләрен куллануга рөхсәтләр бирү (гамәлдән чыгару);

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннарның сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган төрләрен ябып тотуга һәм табигатькә чыгаруга рөхсәтләр бирү (гамәлдән чыгару);

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннарның, үсемлекләр һәм гөмбәләрнең сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган төрләрен үрчетү һәм карап тоту буенча генетик үзәкләрне теркәү;

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннарның, үсемлекләр һәм гөмбәләрнең сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган төрләрен саклау максатларында аеруча сакланыла торган табигый териорияләр оештыру һәм генетика банклары төзү тәкъдимнәрен әзерләү.

2.2. Хайваннарның, үсемлекләрнең һәм гөмбәләрнең сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган төрләре турында мәгълүмат җыю вазыйфаи бурычларына законнар нигезендә мондый эшчәнлекне гамәлгә ашыру кирәк торган Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты белгечләре, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар, фәнни һәм фәнни-тикшеренү учреждениеләре хезмәткәрләре, шулай ук бу өлкәдә дөрес мәгълүматлар җыюны тәэмин итә торган бүтән юридик һәм физик затлар тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертү өчен хайваннарның, үсемлекләрнең һәм гөмбәләрнең сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган төрләре турында мәгълүмат түбәндәге белешмәләрне үз эченә алырга тиеш:

якындагы даими географик ориентирга кадәр (торак пункт, шоссе, күпер һ.б.ш.) юнәлешне һәм ераклыкны күрсәтеп, объектны очратуның төгәл урыны;

очраган объектлар саны, хайваннар төрләре өчен – җенесен күрсәтеп;

объект караган төр;

объектның торышы (җәберләнгәнлек дәрәҗәсе);

тормыш циклы чоры;

респондент күзлегеннән чыгып, билгеле бер әһәмияткә ия булган башка белешмәләр;

респондентның фамилиясе, исеме, әтисе исеме (булганда), адресы (телефоны), эш урыны.

Әлеге белешмәләрне үз эченә алган мәгълүмат анализлау, гомумиләштерү һәм саклау өчен язма яки электрон рәвештә 420021, Казан шәһәре, Кәрим Тинчурин ур., 29 йорт, e-mail: ojm@tatar.ru адресы буенча Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитетының биотөрлелек бүлегенә тапшырыла.

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннарның, үсемлекләрнең һәм гөмбәләрнең сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган төрләре турында мәгълүмат әлеге Нигезләмәгә кушымтага ярашлы рәвештә мәгълүмат карточкасы формасы буенча Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитетына тапшырыла.

Әлеге мәгълүматны саклау Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты архивында гамәлгә ашырыла.

2.3. Хайваннарның, үсемлекләрнең һәм гөмбәләрнең теге яки бу төрләрен Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертү (яки аннан чыгару) турындагы мәсьәләне карап тикшерү, шулай ук тиешле карарлар кабул итүне Комиссия гамәлгә

ашыра. Комиссия кабул иткән карар Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

2.4. Татарстан Республикасының Кызыл китабын басмага әзерләүне, бастырып чыгаруны һәм таратуны Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты һәм Комиссия гамәлгә ашыра. Татарстан Республикасының Кызыл китабын нәшер итү 10 елга кимендә бер тапкыр Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә гамәлгә ашырыла.

2.5. Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннарны һәм үсемлекләрне әйләнештә йөртүгә, ябып асрауга һәм табигатькә реинтродукцияләүгә рөхсәтләрне бирү (юкка чыгару) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.6. Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннарның, үсемлекләрнең һәм гөмбәләрнең сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган төрләре торышын мониторинглауны тәэмин итүне һәм аларны саклау һәм торгызу өчен мәгълүматлар банкын төзү һәм алып баруны сирәк очрый торган хайваннар, үсемлекләр һәм гөмбәләр популяциясенә үткәрелгән скрининг, сан, репродуктив потенциал, репродуктив билгеләр генетикасы, микроэволюцион күчешләр фаразы динамикасы мәгълүматлары даими килеп тору нигезендә Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты гамәлгә ашыра.

2.7. Хайваннарның, үсемлекләрнең һәм гөмбәләрнең Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән төрләрен үрчетү, карап тоту һәм әйләнештә йөртү үзәкләрен теркәү һәм хайваннарның, үсемлекләрнең һәм гөмбәләрнең Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк төрләре турында мәгълүматлар банкын булдыру Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты тарафыннан ул билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

2.8. Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннарның, үсемлекләр һәм гөмбәләрнең сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган төрләрен саклау максатларында аеруча сакланыла торган табигый териорияләр оештыру һәм генетика банклары төзү тәкъдимнәрен әзерләүне Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты гамәлгә ашыра.

___